| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**    с. Тюлячи    **КАРАР**

«8» апрель 2022    № 63

Хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерлек узучы укучылар белән уку-кыр җыеннарын уздыру турында

МКУ «Район Башкарма комитеты мәгариф бүлеге»нең 2022 елның 04 апрелендәге 98 номерлы хатын карап, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 елның 31 декабрендәге 1441 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турында Нигезләмәне, «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә өйрәтүне оештыру инструкциясен раслау турында» 2010 елның 24 февралендәге 96/134 номерлы Россия Федерациясе Оборона министры һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрының приказын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 4 февралендәге 165-р номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Районның урта (тулы) гомуми белем бирү учреждениеләренең 10 сыйныф укучылары белән уку җыеннарын 2022 елның 18-20 май аралыгында уздырырга.

2. Уку җыеннары үткәрү буенча гомуми җитәкчелекне район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга, укучылар белән укыту-кыр дәресләрен оештыру һәм уздыру өчен җаваплылыкны МКУ «ТР Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» башлыгы Н.В. Карповага, кече калибрлы винтовкадан ату күнегүләрен башкаруны оештыру һәм ату вакытында куркынычсызлык чараларын тәэмин итүне, килешү буенча, Татарстан Республикасының армиягә, авиациягә һәм флотка ирекле ярдәм күрсәтү җәмгыяте региональ иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе ҖБ рәисе Р.Р. Нуртдиновка йөкләргә.

3. МКУ «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» (Карпова Н.В.):

- уку җыеннарына җәлеп ителә торган укучыларның составын билгеләргә, район мәгариф учреждениеләренең 10 сыйныф укучыларын - ир-

ат җенесендәге гражданнарын тулы колачлауны тәэмин итәргә, аларны җыю урынына чыгаруны, кайнар туклануны оештырырга, уку процессын урнаштыру һәм оештыруны, хәрби-патриотик тәрбия һәм спорт-массакүләм эше чараларын үткәрүне тәэмин итәргә;

- уку-кыр җыеннарының вакытлы штатына җаваплы затларны билгеләргә һәм аларны җыеннар программасы һәм үз бурычлары белән таныштырырга.

4. Район Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасына (Яхин Р.Р.) транспорт чыгымнарына, җыемнарда катнашучыларны туклandыруга, алдынгы катнашучыларга бирү өчен бүләкләр сатып алуга, аз калибрлы винтовкаларга сугыш кирәк-яраклары сатып алуга, кимерүчеләргә каршы дератизациягә һәм талпаннарның дезинсекциясенә МКУ «ТР Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» сметасы исәбеннән акча бүлеп бирергә.

5. Тәкъдим итәргә:

- ДАССУ «Теләче үзәк район хастаханәсе» баш табибына (Галиуллин И.И.) җыеннарда катнашучыларга медицина хезмәте күрсәтүне оештырырга, җыеннар үткәрелгән урында медицина пунктын җиһазландырырга, аны медицина персоналы һәм «Ашыгыч ярдәм» кизү машинасы белән комплектларга, медикаментлар һәм авыруларны эвакуацияләү чаралары белән тәэмин итәргә;

- Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлеге башлыгы полиция подполковнигына (Зарипов И.С.) җыеннар үткәрү урынында җәмәгать тәртибен һәм иминлекне тәэмин итәргә;

- Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Саба һәм Теләче муниципаль районнары буенча баш белгеченә (Хәкимуллин Л.М.) уку җыеннарында янгын куркынычсызлыгын саклау чараларын үткәрергә;

- урта гомуми белем бирү мәктәпләре директорларына укучыларны уку җыеннарын оештыру урынына имин илтүне һәм аларны тәмамлагач кире алып кайтуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Житәкче И.Х. Хәмидуллин